**СОВЕТ ДЕРЖАВИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422620,Татарстан, с. Державино,
ул. Заббарова, д.39
тел: 3-45-20

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДЕРЖАВИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422620 Державино авылы,
Заббаров урамы, 39 нчы йорт,
тел: 3-45-20

---

**2022 елның 2 декабре** **44 номер**

## КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Державино авыл җирлеге Советының Җирле салымнар буенча салымның вакытында түләнми калган өлешен, пеняларны һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүне өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында 2022елның 28 ноябрендәге 40 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2022 елның 28 декабрендәге 40 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Державино авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә. Әлеге карар закон көченә кергән көннән Державино авыл җирлеге Советының җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында 2019 елның 1 ноябрендәге 23 номерлы карары үз көчен югалткан дип танылa.»

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Державино авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Державино авыл җирлеге Советының план-бюджет комиссиясенә һәм икътисадый үсешенә йөкләргә.

**Башлык - Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Державино
авыл җирлеге - Советы рәисе** **И.И.Камалиева**